ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**«03» март 2020 ел** **№ 126**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура-спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләренә акчалата түләүләр билгеләү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура - спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләренә акчалата түләүләр билгеләү турында» 2019 елның 31 октябрендәге 979 номерлы карарын үтәү йөзеннән Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты булган спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура- спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә түбәндәге акчалата түләүләр билгеләргә:

эшләгән вакытка пропорциональ рәвештә 1111 сум күләмендә, әмма аена 1111 сумнан да артмаган күләмдә, стимуллаштырыла торган өстәмә түләү.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Арча муниципаль районы башкарма комитеты булган спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура - спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә акчалата түләүләр бирү Тәртибен 1 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура-спорт оешмаларында эшләүчеләргә субсидияләр бирү турында килешү формасын 2 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo/tatarstan/ru) һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (http://arsk/tatarstan/ru).

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р. Р. Мөхетдинов

Арча муниципаль районы башкарма
комитетының 03 март 2022 № 126
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Арча муниципаль районы башкарма комитеты булган спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура - спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә акчалата түләүләр бирү Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Арча муниципаль районы башкарма комитеты булган спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура - спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә акчалата түләүләр бирү тәртибен һәм шартларын билгели.

стимуллаштырыла торган өстәмә түләү эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә ай саен 1111 сум күләмендә башкарыла, әмма аена 1111 сумнан да артмый.

2. Оешма хезмәткәрләре-яшь белгечләргә акчалата түләүләр тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында Арча муниципаль районы бюджетына каралган акчалар хисабына башкарыла.

3. Оешмада эшләүче яшь белгеч дип 30 яшькә кадәрге (30 яшьне кертеп) югары белем бирү программалары - бакалавриат, специалитет, магистратура (алга таба-һөнәри белем бирү оешмасы яки югары белем бирү оешмасы) буенча дәүләм аккредитацияле һөнәри белем бирү оешмасын, югары белем бирү оешмасын көндезге уку формасында беренче тапкыр тәмамлаган һәм һөнәри белем бирү оешмасын, югары белем бирү оешмасын тәмамлаган елның 1 ноябренә кадәр һөнәри белем дәрәҗәсе һәм квалификациясе нигезендә хезмәт килешүе буенча физкультура инструкторы, педагог-оештыручы, педагог-психолог, адаптив физик культура буенча инструктор-методист, адаптив физик культура буенча өлкән инструктор-методист, тренер, адаптив физик культура буенча тренер-укытучы, хореограф, күнегүләр процессы администраторы, адаптив физик культура буенча өлкән тренер-укытучы вазыйфаларына эшкә алынган зат санала.

4. Стимуллаштыра торган айлык өстәмә түләү хезмәткәр - яшь белгечләргә эшкә урнашу аеннан соң килгән айның 1 числосыннан билгеләнә һәм әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган вазыйфада өзлексез эшләү шарты белән аны билгеләү датасыннан соң өч ел дәвамында түләнә.

Яшь белгечләргә айлык стимуллаштыра торган өстәмә түләүне билгеләү, туктату, озайту турындагы карар Оешма боерыгы белән раслана.

Хезмәткәр-яшь белгечләргә айлык стимуллаштыра торган өстәмә түләү вакыты түбәндәге очракларда дәвам итә:

Россия Федерациясе Кораллы көчләрендә чакырылыш буенча хезмәт итү яки альтернатив граждан хезмәте узганда;

йөклелек һәм бала табу буенча ял вакытында, балага өч яшь тулганчы;

көндезге формада аспирантурада уку вакытына.

5. Хезмәткәр-яшь белгеч әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган вазыйфага башка оешмага күчкәндә, 30 көннән дә артмаган вакытка эштән туктап тору рөхсәт ителә.

6. Хезмәткәр - яшь белгеч сан үзгәрү яки штат кыскару сәбәпле эштән киткәндә һәм алга таба әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган вазыйфага башка оешмага эшкә урнашканда, 60 көннән дә ким булмаган вакытка ял итү рөхсәт ителә.

7. Яшь белгечләргә айлык стимуллаштыра торган өстәмә түләү яшь белгечнең төп эш урыны буенча гына билгеләнә.

8. Эшче-яшь белгечләргә айлык стимуллаштыра торган өстәмә түләү төп вазыйфа буенча һәм эш әлеге хезмәткәр - яшь белгеч тарафыннан эчке берләшү шартларында башкарылганда билгеләнә, ләкин 1 ставкадан да артмый.

9. Эшче-яшь белгечләргә айлык стимуллаштыра торган өстәмә түләү күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$D = P \times \frac{H_f}{H_n},$$

биредә:

D - хезмәткәрләргә-яшь белгечләргә айлык стимуллаштыра торган өстәмә түләү күләме, сум;

P - яшь белгечләргә аена 1 111 сум күләмендә стимуллаштыручы өстәмә түләү;

Hf - хезмәткәр-яшь белгеч тарафыннан эшләнгән сәгатьләрнең факттагы саны, сәгать;

Hn-спорт резервын әзерләүне оештыру хезмәткәрләренең хезмәт хакының база ставкасы, сәгать нормасы.

10. Оешмалар ай саен, агымдагы елның 5 числосына кадәр, Башкарма комитетка түбәндәге документларны тапшыралар:

Башкарма комитет тарафыннан расланган форма буенча акча түләүләрен гамәлгә ашыруга акча бирү турында гариза;

Башкарма Комитет боерыгы белән расланган форма буенча Оешмада эшләүче яшь белгечләрнең реестрлары.

11. Башкарма комитет әлеге Тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән документларны, эш көннәрендә исәпләнә торган биш көнлек срокта, алар кергән көннән карый.

Оешма әлеге Тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган пакетын яки югарыда аталган пункт таләпләренә туры килми торган документларны тапшырган очракта, Башкарма комитет гаризаны кире кайтара һәм кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, Оешмага биш көн эчендә хәбәр итә.

Гаризаны кире кайтару турында хәбәрнамә алган көннән соң оешма әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үти һәм Тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән документларны кабат тапшыра.

12. Оешма чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү Башкарма комитет тарафыннан әлеге максатларга Оешмага субсидия бирү юлы белән башкарыла. Субсидия Башкарма комитет һәм Оешма арасында төзелгән килешү (алга таба – Килешү) нигезендә, әлеге карар белән расланган формада бирелә (2 нче кушымта).

Килешү әлеге Тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырганнан соң 10 көн эчендә төзелә.

13. Башкарма комитет оешма хезмәткәрләренә - яшь белгечләргә айлык акча түләүләрен тормышка ашыру өчен субсидияләрне Оешмаларның шәхси счетларына күчерә.

14. Оешмалар Башкарма комитетка килешүдә каралган сроклар һәм форма нигезендә эшләүче яшь белгечләргә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру өчен субсидияләрдән файдалану турында хисап тапшыралар.

15. Агымдагы финанс елында оешма тарафыннан файдаланылмаган субсидияләр Татарстан Республикасы бюджетына билгеләнгән тәртиптә күчерелергә тиеш.

16. Оешма тарафыннан субсидияләр бирү шартларын бозган очракта, Башкарма комитетның язмача таләбе нигезендә субсидияләр тиешле таләп алынган көннән соң 10 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

17. Субсидияләр бирү шартларын, шулай ук төзелгән килешүләрнең үтәлешен контрольдә тоту Башкарма комитет һәм «Арча муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы" МКУ тарафыннан башкарыла.

18. Оешмалар оешма хезмәткәрләре- яшь белгечләргә айлык стимуллаштыра торган өстәмә түләүне бирүне Оешмалар тарафыннан билгеләнгән хезмәт хакын түләү вакытында тәэмин итәләр.

Арча муниципаль районы башкарма
комитетының 03 март 2020, №126
карарына 2 нче кушымта

**Килешү № ______**
**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты һәм оешма арасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура -спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә Арча муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү турында**

Арча шәһәре «____» ________2020 ел

Арча муниципаль районы башкарма комитеты, алга таба «Башкарма комитет» дип аталучы, җитәкчесе И.Ә.Галимуллин йөзендә, Нигезләмә нигезендә эш итүче бер яктан, Арча муниципаль районы оешмасы, алга таба «Алучы» дип аталучы, оешма җитәкчесе _______________йөзендә, _______________ нигезендә эш итүче икенче яктан, алга таба “Яклар” дип аталачаклар, Арча район Советының «Арча муниципаль районының 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына бюджеты турында» 289 номерлы карары һәм Арча муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура -спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә акчалата түләүләр билгеләү турында» карары нигезендә әлеге Килешүне төзеделәр.

## 1. Килешү Предметы

1.1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура-спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләренә Арча муниципаль районы бюджетыннан 2020 елда субсидияләр бирү әлеге Килешүнең предметы булып тора.

1.2. Субсидияләр Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы оешмаларына әлеге Килешүдә каралган максатларга бирелә.

1.3. Арча муниципаль районы бюджетыннан Арча муниципаль районы оешмаларына спорт резервын әзерләүче физкультура – спорт оешмаларының яшь белгечләренә акчалата түләү өчен бирелә торган субсидияләр күләме Оешма тарафыннан ай саен бирелә торган гаризалар нигезендә билгеләнә.

## 2. Якларның вәкаләтләре

2.1. Арча муниципаль районы Башкарма комитеты:

2.1.1. 2020 елда Арча муниципаль районы оешмаларына субсидияләр бирүне «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура -спорт оешмаларында

эшләүче яшь белгечләргә акчалата түләүләр билгеләү турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура - спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә акчалата түләүләр бирү Тәртибе нигезендә тәэмин итә.

2.1.2. Әлеге Килешү кысаларында алынган субсидия бирү вакытында билгеләнгән шартларның үтәлешен, шул исәптән субсидиянең максатчан кулланылышын контрольдә тота.

2.1.3. "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы ФБП" МКУга субсидия бирүне туктатып тору турында тәкъдимнәр җибәрә:

субсидия бирү шартларын бозу, шулай ук Алучыга өстәмә түләү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан бирелгән субсидия чыганагы булган Оешманың чыгымнарын гамәлгә ашыру турында ай саен хисап бирмәве очрагында.

2.2. Алучы:

2.2.1. Башкарма комитетка ай саен, хисап чорыннан соң килүче айның 15 числосыннан да соңга калмыйча, яшь белгечләргә айлык стимуллаштыра торган өстәмә түләү чыгымнары һәм әлеге Килешүнең 1 нче кушымтасы нигезендә субсидиядән файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен үтәү турында хисап бирә.

2.2.2. Бюджет законнары нигезендә агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне дәвамында оешманың күрсәтелгән субсидиягә ихтыяҗы булмаганда, Татарстан Республикасы бюджеты кеременә файдаланылмаган субсидия калдыгын кире кайтара.

2.2.3. Башкарма комитет таләбе буенча әлеге Килешү кысаларында алынган субсидияләрне куллану белән бәйле бухгалтерлык исәп-хисап мәгълүматларын тапшыра.

## 3. Якларның җаваплылыгы

3.1. Әлеге Килешү буенча үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, Яклар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

3.2. Алучы субсидия бирү һәм аннан файдалану шартларын үтәмәгән очракта, әлеге Килешүнең 2.2.1, 2.2.3 пунктларында билгеләнгән максатларга туры китереп Министрлыкка тапшырыла торган мәгълүматның дөреслеге һәм үз вакытында тапшырылмавы өчен законнар нигезендә җавап бирә.

## 4. Гомуми нигезләмәләр

4.1. Яклар арасындагы бәхәсләрне сөйләшүләр юлы белән хәл итәләр, ә килешүгә ирешмәгәндә – суд тәртибендә.

4.2. Әлеге Килешүне үзгәртү яклар инициативасы буенча әлеге Килешүгә өстәмәләр рәвешендә Якларның вәкаләтле затлары тарафыннан имзаланган, аның аерылгысыз өлеше булган язма рәвештә гамәлгә ашырыла.

4.3. Килешү Яклар кул куйган мизгелдән үз көченә керә һәм Яклар тарафыннан үз йөкләмәләренең тулысынча үтәлүенә кадәр гамәлдә була.

4.4. Әлеге Килешү ике нөсхәдә төзелде, бер нөсхәсе – Башкарма комитетка, берсе – Алучыга.

## 5. Якларның түләү реквизитлары

| **Башкарма комитет** | **Алучы** |
| --- | --- |
| Җитәкче вазыйфаларын башкаручы | |
| ____________________ | ____________________________ |
| имза | имза |
| М.У. | М.У. |